# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**(III чакырылыш)**

егерме җиденче утырыш

## КАРАРЫ

28 март 2019 ел **№ 169** Теләче авылы

Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең «Татарстан Республикасында 2018 елда кеше һәм гражданның хокукларын саклау турында»гы доклады турында

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Теләче муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесенең «Татарстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең «Татарстан Республикасында 2018 елда кеше һәм гражданның хокукларын саклау турында»гы доклады турында»гы чыгышын тыңлаганнан соң, Теләче муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Теләче муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесенең чыгышын исәпкә алырга.

2. Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының Кеше хокукларын буенча вәкаләтле вәкилнең «Татарстан Республикасында 2018 елда кеше һәм гражданның хокукларын саклау турында»гы докладындагы тәкъдимнәрне тормышка ашыру буенча чаралар күрергә.

3. Теләче муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлекләрен алып баручы милекчелекнең төрле формасындагы предприятиеләргә, оешмаларга, шәхси эшмәкәрләргә кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Теләче муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Карар үтәлешенә контрольлек итүне Теләче муниципаль районы башлыгы урынбасары А. Г. Фәтхуллинга йөкләргә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы И.Ф. Зарипов